**Мәхмүт ГАЗИЗОВ,**
*шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы,*
*1979-80 елларда «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе*

## КАМА ИДЕЛГӘ ЧЫГА

Халкыбызның бүгенге зур эшләре, олы адымнары турында сүз чыктымы, күренекле татар шагыйре Сибгат ага Хәкимнең шигъри юллары искә төшә:

...Бар да хәзер реальләшеп бетте,
Сорау нигә: кайсы иң алдан?
КАМАЗларның каршысына бас та,
Хыялларны аер реальдән...

Әйе, борынгы бабаларыбыз яшәгән бәрәкәтле Чулман–Кама җирләре хәзер үзенең икенче яшьлеген кичерә. Бу – автомобильләр пәһлеваны КАМАЗ туу белән бәйле. Һәр көнне – ярыш, үсеш, һәркайда – фидакарьлек, тырышлык, һәркемдә – якты хыяллар, изге теләкләр. Боларны күрү, бер каләмдәшебез язганча, «дөнья күзен безнең якка» борган шул төзелешләргә үзеңнән дә өлеш кертү күңелдә горурлык хисләре уята, җыр туа, шигырь туа...

Бу төбәктә электән үк матур традицияләр булган, үзенең җырчылары, үзешчән композиторлары барлыкка килгән, музыка мәктәбе ачылган, драма түгәрәкләреннән халык театры үсеп чыккан.

Яшь каләм ияләре дә үз сүзләрен әйтә килгәннәр. Район газетасы каршында әдәбият-иҗат берләшмәсе төзелгән. Тәүге «чирканчык»ны шунда алган берничә иптәш хәзер инде үзләренең мөстәкыйль китапларын чыгардылар, исемнәре өлкә матбугатында билгеле язучылар, шагыйрьләр булып җитлектеләр. «Автобатыр» төзелеше һәм шәһәрнең тизләтелгән үсеше әдәбият-иҗат берләшмәсенә дә яңа көчләр алып килде, эшче сыйныфны үзәккә куеп иҗат ителгән әсәрләр күренә башлады.

Шигырь сөючеләргә тәкъдим ителә торган бу җыентыкның авторлары – Кама автозаводы һәм аның шәһәр яны зонасын төзүче егетләр-кызлар, төрле һөнәр ияләре. Төгәлрәк әйтсәк, Сәлимә Шәрипова – измә-бетон заводы эшчесе, Рафис Хисамиев – балта остасы, Татарстан туфрагын үз итеп, ерак Себердән килгән егет Шәүкәт Сибгатуллин – электрик, Анатолий Цыганов – укытучы, балалар өчен җылы гына шигырьләр язучы Франц Галин – механизатор, Андрей Колчерин – колхозчы, Нәсимә Садыйкова – бетончы, Зәки Насыбуллин – электросварщик, Әхәт Гайнуллин – слесарьлар бригадиры, Равил Вәлиев белән Рәис Риян – төзелеш газетасы журналистлары, Әлфия Шәрәфетдинова – табельчы.... Исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде, ләкин, укучылар өчен беренче чиратта, авторларның профессиясеннән бигрәк, әсәрләре белән танышу кызыклырак булыр.

Халык ихтыяры белән ай үсәсен көн үскән, республикабызның көнчыгыш үзәгенә әйләнгән яшьлек шәһәрендә киләчәктә булачак зур әдәбиятның тәүге адымнары бүген ясала. Беренче эзләрне шушы китап авторлары – безнең әдәбият – иҗат берләшмәсе әгъзалары да салыша. Шунысы куанычлы: чишмәләрдән – инешләр, инешләрдән Кама барлыкка килгән кебек, шигъри чишмәләребез дә челтерәүдән туктамый, авыр юллар үтеп, үз «Кама»сына җыела. Ул да – безнең шигърият Камасы да – зур юлга, киң дөньяга, әдәбият Иделенә чыксын иде...

*Яр Чаллы, 1980 нче еллар.*